**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Вязовка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына керүче Вязовка поселогы торак пунктында**

**2025 елның 24 октябре № 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Вязовка поселогы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

карар кылды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Вязовка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә.
Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:
- Һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (проектка заказ бирү, искесен сүтү һәм Вязовка бистәсендә Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган сугышчыларга яңа һәйкәл кую)

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**

**«Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы**

**А. Г. Томский**